**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 8 февраль № 80

г. Казань

Ел саен «Уылдык чәчү» операциясен
үткәрү турында

Куйбышев һәм Түбән Кама сусаклагычларында һәм аларның бассейннарындагы сулыкларда судагы биологик ресурсларны саклау һәм аларны рациональ файдалануга уңай шартлар тудыру максатларында, «Хайваннар дөньясы турында» 1995 елның 24 апрелендәге 52-ФЗ номерлы Федераль законның 6 һәм $6^1$ статьялары, «Балык тоту һәм судагы биоресурсларны саклау турында» 2004 елның 20 декабрендәге 166-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясы, шулай ук Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының «Идел-Каспий балык хуҗалыгы бассейны өчен балык тоту кагыйдәләрен раслау турында» 2014 елның 18 ноябрендәге 454 нче боерыгы белән җитәкчелек итеп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Ел саен 15 апрельдән 15 июньгә кадәр Татарстан Республикасының су объектларында судагы биологик ресурсларны законсыз алу белән бәйле хокук бозуларга юл куймау буенча «Уылдык чәчү» комплекслы оператив-профилактик операциясен (алга таба – «Уылдык чәчү» операциясе) үткәрергә.

2. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына төбәк әһәмиятендәге аеруча сакланыла торган табигый территорияләрдә урнашкан су объектларына мөнәсәбәттә төбәк әһәмиятендәге аеруча сакланыла торган табигый территорияләрне саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген көчәйтергә.

3. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгына:

су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә, федераль дәүләт күзәтчелегендә булырга тиеш су объектларыннан тыш, шулай ук төбәк дәүләт күзәтчелегендә булырга тиеш су объектларында урнашкан гидроэнергетик объектларның саклау зоналары чикләрендә су куллану һәм яр сызыгы участокларын (шул исәптән куллану гидроэнергетик объектларга тоташкан участокларны) куллануның аерым шартларын үтәүгә төбәк дәүләт күзәтчелеген көчәйтергә;

су объектларына тоташкан, төбәк дәүләт экология күзәтчелегендә булырга тиеш хуҗалык һәм бүтән эшчәнлек объектларында калдыклар белән эш итү өлкәсендә дәүләт күзәтчелеген көчәйтергә;

су объектларында файдалы казылмалар чыгарганда җир асты байлыкларыннан файдалану шартлары турында лицензияле килешүләрне (шартнамәләрне) үтәү өлешендә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләренә мөнәсәбәттә җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, рациональ файдалану һәм саклауга төбәк дәүләт күзәтчелеген көчәйтергә.

4. Татарстан Республикасы Хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану идарәсенә:

су объектларын ташлап калдырылган судагы биологик ресурсларны аулау коралларыннан чистартуны үткәрергә;

ел саен 20 июньгә кадәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына «Уылдык чәчү» операциясе йомгаклары турында мәгълүмат тапшырырга.

5. «Уылдык чәчү» операциясе үткәрү чорында тәкъдим итәргә:

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына:

судагы биологик ресурслар белән законсыз сату итүне булдырмау буенча чаралар күрергә;

атна саен Татарстан Республикасы Хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану идарәсенә әлеге карарга 1 нче кушымтага ярашлы форма буенча Татарстан Республикасының Административ хокук бозулар турында кодексының 3.2 статьясы буенча (сату итү максатларында билгеләнмәгән урыннарда сату итү) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең административ комиссияләре эше турында мәгълүмат тапшырырга;

яр сызыгы участоклары чикләрендә җирләрдән файдалануга муниципаль җир контролен көчәйтү өлешендә эшне активлаштыру;

Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгына үз вәкаләтләре кысаларында территориаль органнарда балык тоту һәм балык продукциясе әйләнеше тармагында бозуларны профилактикалау һәм аларга юл куймау буенча эшне оештырырга;

Балык тоту буенча федераль агентлыкның Урта Идел территориаль идарәсенең Татарстан Республикасы буенча судагы биологик ресурсларга дәүләт контроле, күзәтчелеге һәм аларны саклау бүлегенә балык тоту тармагында хокук бозуларны табу һәм аларга юл куймау буенча чаралар үткәрергә;

Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Кечкенә суднолар дәүләт инспекциясенә балык тоту өчен кечкенә судноларны куллануны булдырмау максатында су акваторияләрен патрульдә тотуны оештырырга;

Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә федераль дәүләт санитария-эпидемиология күзәтчелеге кысаларында балык продукциясен сату урыннарына рейдлар үткәрергә;

Казан районара табигатьне саклау прокуратурасына судагы биологик ресурсларны законсыз тоту фактлары буенча җинаять эшләрен тикшерү барышына күзәтчелекне көчәйтергә.

6. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына, Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгына үтәргә, шулай ук Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгына, Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә, Балык тоту буенча федераль агентлыкның Урта Идел территориаль идарәсенең Татарстан Республикасы буенча судагы биологик ресурсларга дәүләт контроле, күзәтчелеге һәм аларны саклау бүлегенә, Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Кечкенә суднолар дәүләт инспекциясенә тәкъдим итәргә: «Уылдык чәчү» операциясен үткәрү чорында атна саен Татарстан Республикасы Хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану идарәсенә әлеге карарга 2 нче кушымтага ярашлы форма буенча «Уылдык чәчү» операциясе нәтиҗәләре турында мәгълүмат тапшырырга.

7. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына «Уылдык чәчү» операциясе кысаларында үткәрелә торган эшне массакүләм мәгълүмат чараларында даими яктыртуны тәэмин итәргә.

8. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\80.docx

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 8 февраль, 80 нче карарына 1 нче кушымта

Форма

20___ елның «___»_______ торышына Татарстан Республикасының Административ хокук бозулар турында кодексының 3.2 статьясы буенча (сату итү максатларында билгеләнмәгән урыннарда сату итү) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең административ комиссияләре эше турында
мәгълүмат

| Т/с | Муниципаль берәмлек исеме | Административ җаваплылыккка тартылган | | | | Салынган штрафлар суммасы, мең сум | Алынган штрафлар суммасы, мең сум |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | барлы-гы | юридик зат | вазыйфаи зат | граждан | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |

Җитәкченең Ф.И.Ат.и., имзасы ________________________________________________________

F:\KARAR\2016\80-1.docx

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 8 февраль, 80 нче карарына 2 нче кушымта

Форма

20___ елның «___»_______ торышына «Уылдык чәчү» операциясенең күзәтчелек чаралары турында мәгълүмат

| Күзәтчелек органы исеме | Үткәрелгән рейдлар | Катнашкан хезмәткәрләр саны | Билгеле булган бозулар | Алынган тоту кораллары саны | Кузгатылган администра-тив эшләр саны | Билгеле булган җинаятьләр турында мәгълүмат | Кузгатылган җинаять эшләре саны |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | |

Җитәкченең Ф.И.Ат.и., имзасы ________________________________________

F:\KARAR\2016\80-1.docx